**Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр внешкольной работы» Ново-Савиновского района г. Казани**

Рассмотрена на заседании методического объединения отдела «29» августа 2022 г., протокол №_1__

Принята на заседании методического совета «31» августа 2022 г., протокол № 1

УТВЕРЖДАЮ
Директор ЦВР
Ново-Савиновского района г.Казани
________________/А.И. Салимова/
введена в действие приказом
№_105-о_от _31.августа _2022г.

# *ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА СОЦИАЛЬНО-ГУМАНИТАРНОЙ НАПРАВЛЕННОСТИ ЛИТЕРАТУРНО-ПОЭТИЧЕСКИЙ КЛУБ*

# “Аһәң”

В данном документе пронумеровано, прошнуровано и

Возраст обучающихся:
10 – 14лет
Срок реализации: 1 год

Педагог дополнительного образования **Шагараева А. И.**

2022-2023 г.

**Программа**

Түгәрәкнең исеме: әдәби-шигъри клуб “Аһәң”

Өстәмә белем бирү укытучысы: Шагараева А. И.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Төркемнәр | 1 нче төркем | 2 нче төркем |
| 2 | Укучылар саны | 15 | 15 |
| 3 | Сәгатьләр саны | 144 | 144 |
| 4 | Укучыларның яше | 5, 7 класс | 8 класс |

**Аңлатма язуы**

Туган телебез – бик моңлы тел. Туган телнең сыгылмалылыгы, матурлыгы, моңлылыгы шагыйрьләр, язучылар, җырчылар, нәфис сүз осталары өчен генә түгел, ул барыбыз өчен дә кирәк. Күңел байлыгы да җанга телебез аша туплана. Матур итеп сөйләшә белгән кеше матур итеп уйлый белә, матур итеп уйлый белгән кеше матур эшләргә омтыла. «Аһәң» әдәби-шигъри түгәрәгенең тоткан кыйбласы – укучыларны иҗади фикерләргә, туган телдә камил, матур сөйләшергә өйрәтү аркылы татар телен саклау һәм даими кулланылышка кертү. Бүгенге вәзгыятьтә бик мөһим һәм актуаль мәсьәлә бу.

“Аһәң” әдәби-шигъри түгәрәге программасы түбәндәге хокукый-норматив документларга нигезләнеп төзелде:

- Казанның Яна – Савин районындагы “Мәктәптән тыш эш үзәге”нең Укыту программасы, Уставы нигезендә;
- 29.12.2012 273 –ФЗ “Россия Федерациясендә Укыту турында закон” нигезендә;
- РФ Мәгариф министрлыгының 2018 елның 09 ноябре 196 нчы номерлы Карары “ Өстәмә белем бирү программалары буенча эшне оештыру һәм тормышка ашыру тәртибе “ нигезендә;
- “Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары эш тәртибенең төзелеше, эчтәлеге һәм оештыруына санитар – эпидемиологик таләпләр” СП 2.4. 3648-20

Яшь буынга халкыбызның гасырлар буе тупланып килгән рухи байлыгын аңлату өчен, иң беренче чиратта, туган телне камил белүләренә ирешергә кирәк. Бу, үз чиратында, укучыларда туган телне өйрәнүгә теләк һәм кызыксыну булдыруны таләп итеп куя. «Аһәң» әдәби-шигъри түгәрәге эше барышында әлеге актуаль һәм мөһим проблемаларны хәл итү мөмкин.

***Түгәрәкнең максаты:*** укучыларда туган телгә, татар халкына, милләтнең тарихына, милли гореф-гадәтләргә, мәдәни һәм әдәби мираска карата горурлык һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.

***Төп бурычлар:***

- укучыларда татар телен өйрәнүгә теләк һәм кызыксыну булдыру;
- укучыларны иҗатка тарту, аларның иҗади, рухи, әхлакый һәм интеллектуаль үсеше өчен шартлар тудыру;
- укучыларның сөйләм телен, сүз байлыгын, чыгыш ясау осталыкларын камилләштерү.

Әлеге түгәрәктә укучылар татарча әдәби әсәрләрне, татар халкының мәшһүр язучылары һәм шагыйрьләре иҗатын тирәнтен өйрәнәчәк, татарча газета һәм журналларга даими күзәтү ясаячак. Иҗат итү калыплары, шигырь язу үзенчәлекләре белән танышачак; образлы һәм фәлсәфи фикерләү серләренә төшенәчәк; матур һәм аһәңле итеп сөйләргә өйрәнәчәк. Түгәрәк эшчәнлегендә лекция, практикум, тренинг, мастер-класс, иҗади остаханә, дискуссия форматлары кулланылачак.

Түгәрәк эшчәнлеге кысаларында шигъри кичәләр, әдәби-музыкаль кунакханәләр, театральләштерелгән тамашалар, әдәби марафоннар, юбиляр шагыйрьләргә багышланган шигъри флешмоблар һ.б. үткәрелер дип планлаштырыла. “Аһәң” түгәрәге эше барышында күренекле татар шагыйрьләре һәм язучылары, театр һәм эстрада артистлары, нәфис сүз осталары, журналистлар белән очрашуларга зур игътибар биреләчәк.

Нәтиҗә буларак, түгәрәк әгъзалары төрле дәрәҗәдәге әдәби басмаларда язышыр, әдәбият һәм иҗат конкурс-фестивальләрендә уңышлы катнашыр дип көтелә. Укучыларның иң яхшы әсәрләре ел ахырында «Аһәң» әдәби-шигъри түгәрәге чыгарган онлайн-җыентыкта басылачак.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- туган телне теләп һәм зур кызыксыну белән өйрәнү;
- татар теленә, татар халкына, аның тарихына, милли традицияләргә һәм гореф-гадәтләргә карата хөрмәт һәм горурлык хисе формалашу;
- ватанпәрвәрлек хисе, татар халкының әдәби һәм мәдәни мирасына сакчыл мөнәсәбәт формалашу;
- Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның теленә, мәдәниятенә карата хөрмәт, толерантлык хисе формалашу;
- укучыларның коммуникатив һәм оештыру сәләтләрен, иҗади потенциалларын үстерү;
- укучыларның төрле дәрәҗәдәге иҗади бәйгеләрдә уңышлы чыгыш ясавына ирешү;
- түгәрәк эшчәнлегенә әти-әниләрне, татар зыялылары вәкилләрен, массакүләм чараларны җәлеп итү;